БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-54-26, факс: (84368) 2-51-34. E-mail: Baltasi.Rayispolkom@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

«20» 09. 2024 № 01-35/2941

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү**

**1.** Әлеге мәгълүмат белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты (алга таба – проект) буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

**2.** Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

- I өлеш. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе;
- II өлеш. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
- III өлеш. Шәһәр төзелеше регламентлары;
- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар. ЗОУИТ;
- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар.

**3. Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча ачык тыңлаулар 2024 елның 20 сентябреннән 2024 елның 08 октябренә кадәр үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

**5. Гавами тыңлаулар уздырыла торган территория:**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге.

**6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**

- Югары Шубан авылы, Үзәк ур., 31адресы буенча урнашкан Шубан мәдәният йорты-30.09.2024;

- Түбән Шубан авылы, Г. Тукай ур., 13 адресы буенча урнашкан мәчет бинасында-30.09.2024;

- Ярак-Чурма авылы, М. Горький ур., 43 йорт адресы буенча урнашкан Ярак-Чурма авыл клубында - 30.09.2024;

- Гондыр авылы Совет урамындагы 15 нче йорт каршында урнашкан тукталышта - 30.09.2024;

- Зур Лызи 2 нче өлеш, Нагорная урамындагы 18 нче йорт каршында урнашкан балалар мәйданчыгында - 30.09.2024.

**7. Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:**

2024 елның 30 сентябреннән 2024 елның 08 октябре көннәрендә.

**8. Экспозицияләргә килергә мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**

Эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке тәнәфес – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

**9. Катнашучылар тарафыннан гавами тыңлаулар проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**

30.09.2024 – 08.10. 2024 чорында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^1$ маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

- рәсми сайт аша;

- Татарстан Республикасы Балтач районы Башкарма комитетының гавами тыңлауларын оештыручыга язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә түбәндәге адрес буенча: 422250, ТР, Балтач районы, пгт.Балтач шәһ., Ленин ур., 42 й., тел. (84368) 2-51-34 (9.00 дән 17.00 гә кадәр);

- ачык тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язу юлы белән: 422265, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Югары Шубан авылы, Үзәк урам, 70 нче йорт (9.00 дән 17.00 гә кадәр).

РФ ГрК $5^1$ маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларда катнашучыларның

җыелышларын үткәрү барышында язма яисә телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

**10. Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 08 октябрендә уздырырга:

- Югары Шубан авылында 09.30 сәгатьтә Шубан мәдәният йортында, Югары Шубан авылы, Центральная ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан;
- Түбән Шубан авылында 10.00 сәгатьтә Түбән Шубан авылы, Г. Тукай ур., 13 йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында;
- Ярак Чурма авылында 10.30 сәгатьтә, Ярак Чурма авылы, М. Горький ур., 43 йорт адресы буенча урнашкан Ярак Чурма авыл клубында;
- Гондыр авылында 11.00 сәгатьтә Гондыр авылы, Совет урамында 15 нче йорт каршындагы тукталышта,;
- Зур Лызи авылы 2 өлеш, Зур Лызи авылы 2 өлеш, Нагорная урамындагы 18 нче йорт каршында урнашкан балалар мәйданчыгы янында - 11.30 сәгатьтә.

**11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Проект 2024 елның 30 сентябреннән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылачак (baltasi.tatarstan.ru) «Район турында. Җирлек . Шубан авыл җирлеге. Авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» (https://baltasi.tatarstan.ru/pravila_shuban.htm).

**12. Әлеге хәбәрнамәне** Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) **бастырып чыгарырга**.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов